| | |
|---|---|
| **ГЛАВА БОЛЬШЕРУСАКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ УРСАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 07 октябрь Олы Урсак авылы № 2

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында
гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе
буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге Уставының 22 статьясына туры китереп КАРАР КЫЛА:

1.Олы Урсак төп мәктәбендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 20 октябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә. Олы Урсак авылы, Җиһаншин урамы, 74 нче йорт адресы буенча урнашкан Күпфункцияле үзәк бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең Олы Урсак авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 23 октябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"2020 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) авыл җирлеге территориясен төзекләндерү:*

- урамдагы яктырткычларны ремонтлау,моның өчен материаллар сатып алу

- авыл җирлегендә торак пунктлардагы тиешле һәм тиеш булмаган чүплекләр территорияләрен чистарту;

*б) авыл җирлеге чикләрендәге халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- суүткәргеч челтәрен ремонтлау һәм моның өчен материаллар сатып алу;

*в) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

-юлларны норматив хәлгә китерү, моның өчен материаллар сатып алу;

- авыл җирлеге чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту;

*г) ритуаль хезмәт күрсәтүне оештыру, җирләү урыннарын тиешле тәртиптә тоту:*

-зиратларны чистарту һәм төзекләндерү, моның өчен материаллар сатып алу;

« ӨЧЕН» «КАРШЫ»

3.Әлеге карарны Олы Урсак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» бастырып чыгарырга .http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Урсак авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Олы Урсак авыл җирлеге башлыгы Зиннәтуллтин Г.А.

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ БОЛЬШЕРУСАКОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1061673006328
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ Большерусаковского сельского поселения
ИНН 1621003084